**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «15» декабреннән № 514

«Яңа Чишмә муниципаль районында социаль ипотека программасы буенча торак урыннары алуда кичекмәстән ярдәмгә мохтаҗ гражданнарны тану тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 397 нче номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районында социаль ипотека программасы буенча торак урыннары алуда кичекмәстән ярдәмгә мохтаҗлар буларак тану тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын һәм «Республика дәүләт ярдәме кысаларында торак бирү тәртибен камилләштерү буенча алга таба чаралар хакында» 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Яңа Чишмә муниципаль районында социаль ипотека программасы буенча торак урыннары алуда кичекмәстән ярдәмгә мохтаҗ гражданнарны тану тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2021 елның 30 сентябрендәге 397 нче номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районында социаль ипотека программасы буенча торак урыннары алуда кичекмәстән ярдәмгә мохтаҗлар буларак тану тәртибе һәм шартларына түбәндәге эчтәлектәге 7 пункт өстәргә:

«7. Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге иҗтимагый торак комиссиясе карары нигезендә мөрәҗәгать итүчеләрнең - кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ гаиләләрнең гомуми исемлеген төзи, аны Яңа Чишмә муниципаль районы Советына раслауга тапшыра. Кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ затлар исемлеген раслаганнан соң, Яңа Чишмә муниципаль районы башлыгы имзасы белән район Советы Карары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 2 августындагы 366 номерлы карары нигезендә торак урыннары бирү өчен Дәүләт торак фондына җибәрелә.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://www.novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов